**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

Тел./факс: +7(84365) 2-35-82, 2-35-85, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**30 июнь 2023 ел** **№ 11**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 апрелендәге 13 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ маддәсе, 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары нигезендә Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 апрелендәге 13 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә», түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементлары» сүзләрен алып ташларга;

1.2 12 пунктның 2 абзацында «муниципаль программаларның структур элементларына» дигән сүзләрне алып ташларга;

1.3 12 нче пунктның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләрнең саны һәм бишьеллык чорда, ул ташламалар хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламаларны куллануга потенциаль хокуклы түләүчеләр саны яки түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Ф. Нуруллин